КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 27 декабрь г.Казань № 1228

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 ел, 12 ноябрь, 622 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 ел, 12 ноябрь, 622 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 10 декабрь, 706 нчы, 2007 ел, 29 декабрь, 800 нче, 2009 ел, 23 гыйнвар, 35 нче, 2009 ел, 11 декабрь, 849 нчы, 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче, 2011 ел, 31 гыйнвар, 56 нчы, 2011 ел, 5 март, 177 нче, 2011 ел, 18 ноябрь, 947 нче, 2012 ел, 19 июнь, 524 нче, 2012 ел, 5 октябрь, 833 нче, 2013 ел, 19 ноябрь, 893 нче, 2014 ел, 21 апрель, 262 нче, 2014 ел, 9 сентябрь, 656 нчы, 2014 ел, 24 декабрь, 1018 нче, 2015 ел, 4 июнь, 409 нчы, 2015 ел, 7 август, 575 нче, 2016 ел, 3 июнь, 370 нче, 2017 ел, 20 апрель, 232 нче, 2017 ел, 26 сентябрь, 719 нчы, 2018 ел, 27 сентябрь, 869 нчы, 2018 ел, 10 декабрь, 1100 нче, 2018 ел, 29 декабрь, 1295 нче, 2020 ел, 27 май, 426 нчы, 2020 ел, 1 сентябрь, 770 нче, 2020 ел, 12 ноябрь, 1019 нчы, 2021 ел, 20 март, 153 нче, 2021 ел, 20 июль, 618 нче, 2021 ел, 10 август, 699 нчы, 2021 ел, 27 декабрь, 1295 нче, 2022 ел, 11 март, 216 нчы, 2022 ел, 2 ноябрь, 1168 нче, 2022 ел, 26 декабрь, 1416 нчы, 2023 ел, 16 март, 255 нче, 2023 ел, 16 июнь, 721 нче, 2023 ел, 24 август, 1013 нче, 2024 ел, 1 июль, 487 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта:

беренче абзацта «4 266,766» саннарын «4 480,359» саннарына алмаштырырга;

икенче абзацта «1 351,994» саннарын «1 419,669» саннарына алмаштырырга;

өченче абзацта «2 914,772» саннарын «3 060,690» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе турындагы нигезләмәдә:

3.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле 3.3.22 пунктча өстәргә:

«3.3.22. Төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеге гамәлгә ашырыла торган Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән капиталь төзелеш объектлары реестрын алып бара.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.7 һәм 3.8 пунктлар өстәргә:

«3.7. Татарстан Республикасының ведомство буйсынуындагы дәүләт казна, бюджет һәм автоном учреждениеләрен (алга таба – ведомствосындагы учреждениеләр) гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра, шул исәптән:

3.8. Ведомство буйсынуындагы оешмаларда хезмәт законнарының һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актларның үтәлешен ведомство тикшерүендә тотуны гамәлгә ашыра.»;

4.1 пунктта:

4.1.9 пунктча үз көчен югалткан дип танырга;

4.1.14 пунктчага «мәгълүмат» сүзеннән соң «һәм документлар» сүзләрен өстәргә;

5.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«ведомство буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлегенә җитәкчелек итә;

ведомство буйсынуындагы учреждениеләр җитәкчеләрен вазыйфасына билгели һәм вазыйфаларыннан азат итә, алар белән хезмәт килешүләре төзи.».

2. Бу карар (әлеге карарның 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктындагы икенче - бишенче абзацларыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин